СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 25 » февраль 2025 ел** **№ 322**

**2025 елга Арча муниципаль районының муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру фаразлау планын (программасын) раслау турында**

“Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турындагы” 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турындагы” 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законнар, Арча район Советының 2008 елның 27 декабрендәге 224 номерлы (2011 елның 14 октябрендәге 74 номерлы, 2012 елның 17 маендагы 137 номерлы, 2015 елның 28 маендагы 342 номерлы, 2016 елның 12 июлендәге 61 номерлы, 2016 елның 10 ноябрендәге 87 номерлы, 2017 елның 10 ноябрендәге 152 номерлы, 2019 елның 19 сентябрендәге 275 номерлы үзгәрешләр белән) карары белән расланган “Арча муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында” Нигезләмә нигезендә муниципаль милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан Арча район Советы карар кабул итте:

1. Кушымтада бирелгән 2025 елга Арча муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән

халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы җир һәм имлек мәсьәләләре палатасына йөкләргә. йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г.Нуриев

РАСЛАНДЫ
Арча район Советының
«12» февраль 2025 ел № 322
карары белән

**2025 елга Арча муниципаль районының муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру ФАРАЗЛАУ ПЛАНЫ (ПРОГРАММАСЫ)**

## I бүлек. Мөлкәтне хосусыйлаштыру өлкәсендәге төп юнәлешләр

2025 елга Арча муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) (алга таба – хосусыйлаштыру программасы) гамәлгә ашыруның төп максаты – муниципаль милекюелән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру.

2025 елда муниципаль милекне хосусыйлаштыру “Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турындагы” 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турындагы” 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законнар, Арча район Советының 2008 елның 27 декабрендәге 224 номерлы (2011 елның 14 октябрендәге 74 номерлы, 2012 елның 17 маендагы 137 номерлы, 2015 елның 28 маендагы 342 номерлы, 2016 елның 12 июлендәге 61 номерлы, 2016 елның 10 ноябрендәге 87 номерлы, 2017 елның 10 ноябрендәге 152 номерлы, 2019 елның 19 сентябрендәге 275 номерлы үзгәрешләр белән) карары белән расланган “Арча муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында” Нигезләмә, 2017 елның 22 июнендәге Татарстан Республикасы Җир һәм милек мөнәсәбәтләре министрлыгы һәм “Арча муниципаль районы” муниципаль берәмлеге арасында үзара хезмәттәшлек турында килешү белән тормышка ашырылачак.

1. 2025 елда мөлкәтне хосусыйлаштыру бурычлары.

Агымдагы елда мөлкәтнене хосусыйлаштыру бурычлары булып:

- район икътисадында структур үзгәртеп коруларны дәвам итү;
- муниципаль милек структурасын оптимальләштерү;
- район икътисадының чын секторына инвестицияләр җәлеп итүне стимуллаштыру;
- муниципаль милек объектларын хосусыйлаштыруның максималь бюджет нәтиҗәлелеген тәэмин итү;

- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү тора.

2. Район икътисадында структур үзгәрешләргә, шул исәптән икътисадның конкрет тармакларына (идарә өлкәләрендә) хосусыйлаштыруның йогынтысы фаразы.

Гомумән алганда, 2025 елга Арча районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планында (программасында) күрсәтелгән мөлкәт объектларын хосусыйлаштыру район икътисадындагы, шул исәптән икътисадның конкрет тармакларындагы (идарә өлкәләрендәге) структур үзгәрешләргә йогынты ясамаячак.

3. Муниципаль милекне сатудан алынган акчаларның Арча муниципаль районы бюджетына керүе фаразы.

Арча районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразланган планы (программасы) нигезендә 2025 елга 7 күчемсез мөлкәт объектын һәм 12 күчемле мөлкәт объектын хосусыйлаштыру күздә тотыла.

Муниципаль күчемсез һәм күчемле мөлкәт объектларын хосусыйлаштырудан Арча муниципаль районы бюджетына керемнәр кимендә 1500,00 мең сум тәшкил итәчәк дип планлаштырыла.

## II бүлек. 2025 елда хосусыйлаштырырга планлаштырыла торган муниципаль мөлкәт исемлеге

| № п/п | Милкнең исеме һәм урнашу урыны | Характеристика |
|---|---|---|
| 1. | Венета авылы,Үзәк ур., 13 йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге булган административ бина | Бер катлы, гомуми мәйданы 57,5 кв. м. |
| 2. | Сикертән авылы, Мәктәп урамы, 79 йорт адресы буенча урнашкан административ бина һәм җир кишәрлеге булган котельная бинасы | Административ бина – бер катлы, гомуми мәйданы 120,1 кв. м.; котельная бинасы – бер катлы, гомуми мәйданы 16,1 кв. м. |
| 3. | Арча районы, Ташкичү авылы, Ленин ур., 71 йорт адресы буенча урнашкан торак булмаган бина (ФАП) | Бер катлы, гомуми мәйданы 117,9 кв. м. |
| 4. | Кушлавыч авылы, Тукай ур., 62 йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге булган китапханә бинасы | Бер катлы, гомуми мәйданы 85,1 кв. м. |

| | | |
|---|---|---|
| 5. | Арча муниципаль районы, Шурабаш авылы, Гагарин ур., 17 йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге булган административ бина | Бер катлы, гомуми мәйданы 230,5 кв. м. |
| 6. | Арча муниципаль районы, Кече Төрнәле авылы, Г. Тукай ур., 14 йорт адресы буенча урнашкан башлангыч мәктәп бинасы һәм җир кишәрлеге булган котельная бинасы | бина – бер катлы, гомуми мәйданы 49,3 кв. м.; котельная бинасы – бер катлы, гомуми мәйданы 9,9 кв. |
| 7. | Арча районы, Гөберчәк авылы, М. Мәһдиев ур., 72 А йорт адресы буенча урнашкан торак булмаган бина | Бер катлы, гомуми мәйданы 95,3 кв. м. |
| 8. | Пежо Боксер (дәүләт номеры АУ 071 16) | 2013 елда чыккан |
| 9. | CHEVROLET NIVA, (дәүләт номеры А 730 КМ 716 RUS)<br>VIN X9L212300J0644683 | 2017 елда чыккан, төсе куе соры металл |
| 10. | FIAT DUCATO, (дәүләт номеры ВТ 402 16 RUS )<br>VIN Z7G244000BS030475 | 2011 елда чыккан, төсе Сары |
| 11. | CHEVROLET NIVA, (дәүләт номеры У 449 ВА 116 RUS)<br>VIN X9L212300E0529384 | 2014 елда чыккан, төсе ачык көмешсыман металл |
| 12. | Көпчәкле трактор Белорус 82.1 | 2013 елда чыккан, төсе зәңгәр |
| 13. | FORD EXPLORER (дәүләт номеры М 108УТ 716 RUS)<br>VIN Z6FBXXESWBEP21487 | 2014 елда чыккан, төсе ак |
| 14. | CHEVROLET NIVA, (дәүләт номеры Х 110 ВО 116 RUS)<br>VIN X9L212300F0570406 | 2014 елда чыккан, төсе ачык көмешсыман металл |
| 15. | Ford Фокус (дәүләт номеры В048 ХА 716 RUS)<br>VIN X9FMEEBMCT75854 | 2012 елда чыккан, төсе куе зәңгәр |
| 16. | HYUNDAY SONATA 2.0 (дәүләт номеры У272 РУ 716 RUS)<br>VIN KMHEU41ABAA783216 | 2010 елда чыккан, төсе көмешсу |
| 17. | CHEVROLET NIVA, (дәүләт номеры А 769 КМ 716 RUS)<br>VIN X9L212300J0644551 | 2017 елда чыккан, төсе куе соры металл |

| | | |
|---|---|---|
| 18. | CHEVROLET NIVA, (дәүләт номеры Е 372 КР 716 RUS)<br>VIN X9L212300L0698717 | 2019 елда чыккан, төсе куе соры металл |
| 19. | Чапкыч КРН-2,1 Б | 2022 елда чыккан |
| 20. | Түбәндәге адрес буенча урнашкан, җир кишәрлеге булган балалар бакчасы бинасы: Арча районы, | 140,2 кв.м. гомуми мәйданлы |